ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/14

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр  Советының
9/14 Карарына кушымта
3 ноябрь, 2021 ел.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә  Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне (алга таба – муниципаль контроль) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгели.

2. Муниципаль контроль предметы булып торалар:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар һәм оешмалар  (алга таба – контрольдә тотылучы затлар) тарафыннан төзекләндерү Кагыйдәләрен  үтәү (алга таба – Кагыйдәләр), шул исәптән  социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен ужайлыгын тәэмин итүгә карата таләпләр;

2) контроль чараларының нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның үтәлеше.

3. Муниципаль контроль предметына Кагыйдәләрдә билгеләнгән, гамәлдәге законнар нигезендә дәүләт контроленең, муниципаль контрольнең башка төрләре предметы булган  мәҗбүри таләпләр керми.

4. Муниципаль контроль объектлары (алга таба – контроль объекты) булып тора:

1) контрольдәге затлар ия булган һәм (яки) аннан файдаланган (алга таба-җитештерү объектлары) биналар, корылмалар, җир участоклары, линия объектлары, алар янәшәсендәге территорияләр, төзекләндерү элементлары, гомуми файдаланудагы территорияләр;

2) җитештерү объектларын, гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм төзекләндерү тәртибен үтәү буенча контрольдәге затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәл кылмавы), шулай ук мондый эшчәнлек нәтиҗәләре.

5. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләте бирелгән орган (алга таба – Контроль орган) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, әлеге Нигезләмә нигезендә контроль объектларын исәпкә алуны тәэмин итә.

6. Контроль объектларын исәпкә алу Контроль орган тарафыннан Контроль орган җитәкчесе тарафыннан расланган типлаштырылган форма нигезендә рәсмиләштерелә торган контроль объектларын исәпкә алу журналын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла.

7. Исәпкә алу максатларында контроль объектлары турында мәгълүматларны җыю, эшкәртү, анализлау һәм исәпкә алганда, Контроль орган норматив хокукый

актлар нигезендә бирелә торган мәгълүматны, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына торган мәгълүматны, шулай ук һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны куллана.

8. Контроль объектларын исәпкә алганда, контрольдәге затларга, федераль законнарда башкасы каралмаган булса, шулай ук тиешле мәгълүматлар, документлар дәүләт яки муниципаль мәгълүмат ресурсларында булса, мәгълүмат, документлар бирү бурычы йөкләнә алмый.

9. Контроль объектларын һәм алар белән бәйле контрольдәге затларны исәпкә алу мәгълүмат системалары булдыру юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

10. Муниципаль контроль Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

11. Контроль орган исеменнән муниципаль контрольне түбәндәге вазыйфаи затлар башкарырга хокуклы:

1) җитәкче (җитәкче урынбасары);

2) әлеге Нигезләмә, вазыйфаи регламент яисә вазыйфаи инструкция нигезендә муниципаль контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән профилактик чаралар һәм контроль чаралар үткәрү кергән Контроль органның вазыйфаи заты (алга таба-инспектор).

12. Контроль органның контроль чарасын үткәрү турында карар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

1) җитәкче;

2) җитәкченең беренче урынбасары;

3) җитәкче урынбасары.

13. Конкрет профилактик чараны яисә контроль чараларын үткәрүгә вәкаләтле инспекторлар контроль органның профилактик яисә контроль чара үткәрү турында карары белән билгеләнә.

14. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда инспекторлар «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә хокукларга, бурычларга һәм җаваплылыкка ия.

15. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, профилактик чараларны, контроль чараларын оештыру һәм үткәрү белән бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## 2. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы белән идарә итү

16. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда куркынычлар белән идарә итү һәм бәяләү системасы кулланылмый.

## 3. Закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычларын профилактикалау

17. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль орган түбәндәге профилактик чаралар үткәрә:

1) мәгълүмат бирү;

2) консультация бирү.

18. Мәгълүмат бирү Контроль орган тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кагыйдәләрдәге таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча мәгълүматларны Контроль органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында, массакүләм мәгълүмат чараларында, контрольдәге затларның шәхси кабинетлары аша (алар булганда) һәм башкача урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

19. Контроль органның вазыйфаи заты контрольдәге затларның һәм аларның вәкилләренең мөрәҗәгатьләре буенча консультацияләр бирә (муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә). Консультация бирү түләүсез башкарыла.

20. Консультация бирү телефон аша, видео-конференция элемтәсе аша, шәхси кабул итү яки профилактик чара, контроль чаралары уздыру барышында башкарылырга мөмкин.

21. Контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү мәсьәләләре:

1) контроль чаралар үткәрү тәртибе;

2) контроль чаралар үткәрү вакыты;

3) контроль чаралар йомгаклары буенча карарлар кабул итү тәртибе;

4) Контроль орган карарларына шикаять бирү тәртибе.

22. Консультация биргәндә контроль органның вазыйфаи заты Россия Федерациясе законнары нигезендә куллану чикләнгән мәгълүматның конфиденциальлеген үтәргә тиеш.

23. Консультация барышында конкрет контроль чарасына, контроль органның вазыйфаи затларының, контроль чарасының башка катнашучыларының карарларына һәм (яки) гамәлләренә бәя биргән мәгълүмат, шулай ук контроль чаралары кысаларында үткәрелгән экспертиза, сынауларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирелә алмый.

24. Консультация барышында Контроль органның вазыйфаи затына билгеле булган мәгълүмат Контроль орган тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча контрольдәге затны бәяләү максатында кулланыла алмый.

25. Контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация нәтиҗәләре буенча язма рәвештә мәгълүмат бирелми, Контроль органга контрольдәге затлардан «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән срокларда язма җавап бирү кирәклеге турында язма мөрәҗәгатьләр керү очракларыннан тыш.

26. Календарь ел дәвамында биш һәм аннан да күбрәк бер типтагы мөрәҗәгать кергән очракта, контрольдәге затларга һәм аларның вәкилләренә консультация бирү Контроль органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында Контроль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) кул куйган язма аңлатма урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

27. Контроль орган консультация бирү исәбен консультация журналына язу юлы белән алып бара, аның формасы Контроль орган җитәкчесе тарафыннан раслана.

28. Профилактик чаралар ел саен раслана торган закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасы нигезендә Контроль органның вәкаләтле вазыйфаи заты карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Контроль орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 4. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру

29. Контроль органның, аның вазыйфаи затларының контрольдәге затлар белән үзара хезмәттәшлегенә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда инспектор һәм контрольдәге зат яки аның вәкиле арасында очрашулар, телефон аша һәм башка сөйләшүләр (турыдан-туры бәйләнеш), документлар, башка материаллар соратып алу, инспекторның контрольдәге затның эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынында булуы (инспекторның ирекле керү мөмкинлеге булган җитештерү объектларында булу очракларыннан тыш) керә.

30. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында, контрольдәге зат белән берлектә, түбәндәге контроль чаралар үткәрелә:

1) инспекция визиты;
2) рейд тикшерүе;
3) документар тикшерү;
4) күчмә тикшерү.

31. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында контрольдәге зат белән үзара бәйләнешсез рәвештә түбәндәге контроль чаралар үткәрелә:

1) мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү;
2) күчмә тикшеренү.

32. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда планлы контроль чаралар үткәрелми.

33. Планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралары «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган нигезләр булганда, прокуратура органнары белән килештереп үткәрелә.

34. Планнан тыш контроль чаралары :

1) инспекция визиты;
2) рейд тикшерүе;
3) документар тикшерү;
4) күчмә тикшерү.

35. Планнан тыш контроль чарасының конкрет төре һәм эчтәлеге (контроль гамәлләр исемлеге) планнан тыш контроль чараларын үткәрү турындагы карарда билгеләнә.

36. Инспекция визиты контрольдәге затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләре) яисә күзәтчелек объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урыны буенча үткәрелә.

37. Инспекция визиты барышында түбәндәге контроль гамәлләрне кылырга мөмкин:

1) карау;

2) сораштыру;

3) язмача аңлатма алу;

4) инструменталь тикшерү;

5) мәҗбүри таләпләр нигезендә контрольдәге затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләрнең) яисә контроль объектының урнашу (эшчәнлек алып бару) урынында булырга тиешле документларны таләп итү.

38. Инспекция визиты контрольдәге затка алдан хәбәр итмичә үткәрелә.

39. Бер урында яки бер җитештерү объектында (территориядә) инспекция визитын үткәрү вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

40.Рейд тикшерүе контроль объектына ия булган, аннан файдаланган яки идарә итү белән шөгыльләнгән барлык контрольдәге затларга, яки билгеле бер территориядә эшчәнлек алып баручы яки гамәл кылучы контрольдәге затларның чикләнмәгән даирәсенә карата үткәрелә.

41. Рейд барышында түбәндәге контроль гамәлләрне кылырга мөмкин:

1) карау;

2) сораштыру;

3) язмача аңлатма алу;

4) документлар таләп итү;

5) инструменталь тикшерү.

42. Рейд тикшерүе вакытында бер контрольдәге зат белән узара бәйләнеш вакыты бер эш көненнән дә артмаска тиеш.

43. Документар тикшерү барышында контрольдәге затларның контроль орган карамагында булган документлары, алдагы контроль чаралар нәтиҗәләре, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материаллары һәм контрольдәге зат тарафыннан муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында башка документлар карала.

44. Документар тикшерү барышында түбәндәге контроль гамәлләр кылырга мөмкин:

1) язмача аңлатмалар алу;

2) документлар таләп итү.

45. Документар тикшерү үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш. Күрсәтелгән срокка кертелми:

1) Контроль орган тарафыннан контрольдәге затка документар тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны сорап таләп җибәргән вакыттан алып, Контроль органга әлеге таләп нигезендә документларны тапшырганга кадәр вакыт;

2) Контроль орган тарафыннан контрольдәге затка бирелгән документларында табылган хаталар һәм (яки) каршылыклар, яисә бу документлардагы мәгълүматның контроль органда булган документлардагы һәм (яки) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган мәгълүматка туры килмәве турында аңлатмаларны язма рәвештә тапшыру зарурлыгы турында хәбәр

җибәргән вакыттан алып әлеге аңлатмаларны контроль органга тапшырганга кадәр вакыт.

46. Күчмә тикшерү җитештерү объектларына ия һәм (яки) алардан файдаланучы конкрет контрольдәге зат белән бәйләнештә, мондый зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен бәяләү, шулай ук контроль органы карарлары үтәлешен бәяләү максатларында үткәрелә.

47. Күчмә тикшерү барышында түбәндәге контроль гамәлләрне кылырга мөмкин:

1) карау;

2) сораштыру;

3) язмача аңлатма алу;

4) документлар таләп итү;

5) инструменталь тикшерү.

48. Күчмә тикшерүне үткәрү вакыты ун эш көненнән дә артмаска тиеш. Бер кече эшмәкәрлек субъектына карата күчмә тикшерү барышында үзара бәйләнешнең гомуми вакыты кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артмаска тиеш. Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмага карата күчмә тикшерү үткәрү срогы оешманың һәр филиалы, вәкиллеге, аерым структур бүлекчәсе яисә җитештерү объекты буенча аерым билгеләнә.

49. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) дигәндә Контроль органда булган контроль объектлары турында, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кергән мәгълүматларны, мәҗбүри таләпләрне үтәү кысаларында, контрольдәге затлар тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларындагы мәгълүматларны, «Интернет» челтәрендәге, файдалану өчен ачык булган башка мәгълүматларны, шулай ук фото һәм кино төшерү, видеоязма функцияләренә ия булган хокук бозуларны теркәүнең автоматик режимында эшләүче техник чараларыннан алынган мәгълүматларны җыю, анализлау аңлашыла.

50.Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәткәндә (куркынычсызлык мониторингы), контрольдәге затларга мәҗбүри таләпләрдә билгеләнмәгән бурычлар йөкләнә алмый.

51.Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында зыян (зарар) китерү яки закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычы янау фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне бозуга әзерлек турында яки мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында мәгълүмат ачыкланса, контроль орган тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителергә мөмкин:

1) планнан тыш тикшерү чарасын үткәрү турында карар;

2) кисәтү игълан итү турында карар;

3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар.

52. Күчмә тикшерену дигәндә контрольдәге затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүне бәяләү максатларында үткәрелә торган контроль чарасы аңлашыла.

53. Күчмә тикшерену оешманың (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерым структур бүлекчәләрнең) урнашу (эшчәнлек алып бару), гражданның эшчәнлек алып бару урыны, контроль объектының урнашу урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдәге зат белән үзара бәйләнеш рөхсәт ителми.

54. Чикләнмәгән затлар даирәсенә керү өчен ачык булган җитештерү объектларында күчмә тикшерену барышында түбәндәге гамәлләрне кылырга мөмкин:

1) карау;

2) пробалар (үрнәкләр) сайлап алу;

3) инструменталь тикшерү (видеоязма кулланып);

4) сынау;

5) экспертиза.

55. Күчмә тикшерену контрольдәге затка мәгълүмат бирмичә үткәрелә.

56. Бер объектта (бер-берсенә якын урнашкан берничә объектта) күчмә тикшерену уздыру вакыты, әгәр контроль рәвешендәге Федераль законда башкача билгеләнмәгән булса, бер эш көненнән артмый.

57. Контрольдәге затлар булып торучы шәхси эшмәкәргә, гражданинга контроль чарасын үткәргәндә катнашу мөмкинлеге булмау турында контроль органга хәбәр итәргә хокук бирә торган очраклар:

1) медицина учреждениесендә стационар дәваланууда булу;

2) Россия Федерациясеннән читтә булу;

3) тикшерү чарасын үткәргәндә катнашуга комачаулый торган котылгысыз хәлләр (хәрби гамәлләр, катастрофа, табигать бәла-казасы, зур авария, эпидемия һәм башка гадәттән тыш хәлләр) килеп чыгуы.

58. Әлеге Нигезләмәнең 57 пунктында күрсәтелгән очраклар турында мәгълүмат үз эченә алырга тиеш:

1) хәлләрне һәм аларның дәвамлылыгын тасвирлау;

2) контроль чарасын үткәргәндә катнашмау һәм катнашуга комачаулык тудырган хәлләр арасындагы сәбәп-тикшерү элемтәсе турында белешмәләр;

3) контроль) чарасы уздырганда катнашуга комачаулаучы хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытны күрсәтү.

59. Әлеге Нигезләмәнең 57 пунктында күрсәтелгән очракларда контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү контроль органы тарафыннан шәхси эшмәкәргә, гражданга контроль органга мөрәҗәгать итү өчен сәбәп булган хәлләрне бетерү өчен кирәкле вакытка күчерелә.

60. Мәҗбүри таләпләрне бозуларны дәлилләү өчен инспектор һәм контроль (күзәтчелек) гамәлләрен кылуга җәлеп ителә торган затлар тарафыннан фото төшерү, аудио-һәм видеоязма, дәлилләрне теркәүнең башка ысуллары кулланыла, теркәү тыела:

1) Россия Федерациясе законнары белән дәүләт серенә кертелгән белешмәләр;

2) Россия Федерациясе законнары белән режимлы һәм аеруча мөһим объектларга кертелгән объектлар, территорияләр.

61. Дәлилләрне теркәү өчен кулланыла торган фоторәсемнәр, аудио - һәм видеоязмалар, мәҗбүри таләпләрне бозуны, объектны теркәү вакытын идентификацияләргә мөмкинлек бирергә тиеш.

62. Мәҗбүри таләпләрне бозуны дәлилләү өчен кулланыла торган фоторәсемнәр, аудио - һәм видеоязмалар контроль чаралары актына теркәлә.

63. Контроль чаралары нәтиҗәләре «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелә.

64. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән контроль орган карарларын үтәү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## 5. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү

65. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын бәяләү контроль чаралар үткәргәндә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре системасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

66. Контроль орган эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре системасына керә:

1) алар буенча максатчан (план) күрсәткечләр билгеләнә торган һәм контроль орган аларга ирешүне тәэмин итәргә тиеш булган, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыянны (зарарны) минимальләштерү дәрәҗәсен, тиешле эшчәнлек өлкәсендә зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсен чагылдыра торган контроль төренең төп күрсәткечләре

2) контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген мониторинглаганда, анализлаганда, аны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган проблемаларны ачыклау һәм зыян (зарар) китерү куркынычын бетерү дәрәҗәсе белән хезмәт, матди һәм финанс ресурслары күләме арасындагы чагыштыруны характерлый торган сәбәпләрне билгеләү өчен кулланыла торган контроль төренең индикатив күрсәткечләре, шулай ук контрольдәге затлар эшчәнлегенә катнашу дәрәҗәсе

67. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан күрсәткечләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль өчен индикатив күрсәткечләр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәнең кушымтасында күрсәтелгән.

## 6. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү

69. Контроль орган карарларына һәм вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү законнарда каралган тәртиптә башкарыла

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә төзекләндерү
өлкәсендә муниципаль контроль
турында Нигезләмәгә кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыгы,индикатив күрсәткечләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең төп күрсәткечләре һәм аларның максатчан зурлыгы:

| Төп күрсәткечләр | Максатчан зурлык % |
|---|---|
| Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозу санынннан бетерелгән бозу проценты | 70-80 |
| Контроль орган һәм (яки) аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләр проценты | 0 |

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольнең нндикатив күрсәткечләре:

1) Контроль органга контрольдәге затлардан кергән мәҗбүри таләпләрне бозу турында мөрәҗәгатьләр _______________;

2) Контроль орган тарафыннан планнан тыш үткәрелгән тикшерү чаралары саны _____________;

3) Контроль орган тарафыннан планнан тыш тикшерү чарасын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар саны ______________;

4) Контроль орган тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны ачыклау очраклары саны __________;

5) бетерелгән мәҗбүри таләпләрне бозу саны __________;

6) контроль чарасы актына карата кергән килешмәү саны ___________;

7) мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында Контроль орган тарафыннан бирелгән күрсәтмәләрнең саны ________________ .